

Үткән ял конендә Рузаевка районына 98 яшь тулды. Һәм, традиция буенча, бәйрәмне быел да «Кургоня» XII мордва кунакчыллыгы фестивале белән берләштерделәр. Бәйрәмдә Мордовия Главасы Артём Здунов катнашты.

Россия халыкларынын бердәм-леге елында vткән фестиваль милләтара багланышларны ныгытырга һәм жиребездә гасырлар буе барлыкка килгән традицияләрнен байлыгын сакларга ярдәм итә.



Татар-Пешлә клубынын ижат коллективы бәйрәмдә татар мә-дәниятен тәкъдим итте. Фестиваль кунаклары милли традицияләр белән таныша, татар ашларыннан авыз итә һәм халык уеннарында катнаша алдылар. Программаны «Матур кызлар», «Сандугачлар», «Мелодии души» вокаль ансамбльләре, «Жаным» дуэты һәм солистка Надия Безрукова чыгышлары бизәде.



Чарада Татар-Пешлә клубы мо-дире Наталья Анатольевна Чалдаевага Мордовия Республикасы Главасы Рәхмәт хатын Артём Здунов vзе тапшыруы моһим вакыйга булды. Югары бvләк ана ирешкән хезмәт унышлары һәм мәдәният олкәсендә намуслы хезмәте очен бирелде.

Фестиваль дуслык һәм кунакчыллык атмосферасында узды, катнашучыларда һәм тамашачыларда ин жылы тәэсирләр калдырды.